СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

28.06.2024 № 47/1

На №__________от______________

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына җирлекләрнең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

## КАРАР БИРДЕ:

Боерган, Борды, Иштирәк, Калмаш, Калмия, Князево, Комсомолец, Круглое Поле, Күзкәй, Кече Шилнә, Мәләкәс, Мусабай-Завод, Түбән Суыксу, Яңа Троицкий, Сәмәкәй, Иске Абдул, Иске Дөреш, Теләнче-Тамак, Шилнәбаш, Яңа Бүләк авыл җирлекләре вәкиллекле органнарының Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча күрсәтелгән җирлекләрнең түбәндәге вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында тәкъдимен кабул итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына:

Тукай муниципаль районы җирлекләренең башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне кушымта нигезендә типлаштырылган форма буенча тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатында, бюджет законнары нигезендә 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар планы чорына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты турында Тукай муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында карар проектын эшләргә һәм карауга тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнары үз компетенциясе чикләрендә әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән

Килешүне гамәлгә ашыру өчен норматив һәм норматив булмаган хокукый актлар чыгарырга хокуклы дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http:tukay.tatarstan.ru веб-адресы буенча районның рәсми сайтында һәм һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми игълан итәргә.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров